**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 136**

**21.09.2018 ел**

**«Гражданнарның үзара салымы турында» 2014 елның 05 февралендәге 118 номерлы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Уставына таянып, Түбән Биш авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Гражданнарның үзара салымы турында» 2014 елның 05 февралендәге 118 номерлы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советы карары белән расланган Түбән Биш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. II бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 6 пунктны өстәргә:
«6. Гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе авыл җирлеге башкарма комитеты кабул иткән муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.»;
1.2. III бүлекне төшереп калдырырга.
2. Карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Д.В.Насертдинов**